# КАРАР

**“10” ноябрь 2020 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Кушлавыч авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- 8 Март урамында суүткәргеч челтәр коесы өчен люк капкачы сатып алу-1 данә;
-Тукай-8 Март урамнары киселешендә Кызыл елгасы аша җәяүлеләр күпере ясау өчен материаллар сатып алу;
- юл-урам челтәрен тигезләү өчен вак таш сатып алу.

« ӘЙЕ» “КАРШЫ“

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 97 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 75 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 75 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар- Аты авыл җирлегендә Кушлавыч авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2««Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- 8 Март урамында суүткәргеч челтәр коесы өчен люк капкачы сатып алу-1 данә;

-Тукай-8 Март урамнары киселешендә Кызыл елгасы аша җәяүлеләр күпере ясау өчен материаллар сатып алу;

- юл-урам челтәрен тигезләү өчен вак таш сатып алу.

ӘЙЕ» -75 “КАРШЫ“-0

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 63 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Утар - Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева